Ләбиб Лерон

# Җил көймәсе

Шигырьләр



Рәссамы — Светлана Ибраһимова

Казан
«Мәгариф» нәшрияты
2009



## Сокланыч дөнья

Соклангыч та соң бу дөнья —
Кояшы бар, ае бар...
Чәчәк җыеп йөри сыман
Аланлыкта каеннар...

Үләннәрнең баш очында
Уйный күгелҗем рәшә...
Яшел күктә, йолдызлар күк,
Җиләкләр җемелдәшә...

Күбәләкләр, бөтерелеп,
Чәчәкләргә куналар...
Ак тузганак болытлары
Офыкларга юл ала...

## Онытмам

Дөнья күрәсе иде,
Илләр гизәсе иде —
Диңгезләрдә көймә белән,
Их, бер йөзәсе иде!

Хыялым шундый татлы,
Уйларым матур, якты:
Кайда гына булсам да мин,

Онытмам туган якны!



## Җил көймәсе

Ясадым мин ак кәгазьгә
Сап-сары күл рәсемен.
Күл түгел лә,
Чүл рәсемен!
Күрәсезме?!
Ә-ә-әнә сары
Чүл өстендә
Йөзеп бара
Кәгазь көймә...
Сары дулкын,
Сары эзләр,
Суырылып,
Арттан килә.

...Йөзә көймә.
Куркып куям:
«Җилләр күккә чөймәсме?»
Чөйсә чөйсен, димен аннан,
Ул бит — чүл көймәсе.
Җил көймәсе!



# Матур төш

...Елга өсте — зәңгәр сәхнә, имеш.
Яшел чаршау,— имеш, камышлар.
Су читендә — залда утырганнар
Һәммәсе дә,— имеш, танышлар.
Мин дә шунда, залда,
Карап торам,
Чалбар балакларын сызганып:
Бии, бии яңгыр малайлары,
Бии, бии яңгыр кызлары!..
Зәңгәр сәхнә.
Сальто ясый әнә
Көмеш тәнле ялтыр балыклар;
Шадра бөҗраларның уртасыннан
Шатлык булып чәчри ак чыклар...
Яңгыр җиле шаян көй сызгыра,
Яшел бака җырлый, моңланып.
Чыш-пыш килә талның яфраклары, —
Ак дулкыннар тыңлый, тын калып.
Бии, бии яңгыр малайлары,
Бии, бии яңгыр кызлары!..
Мин кул чабам...
...Һәм уянып китәм.
Кояш чыгып килә, кызарып.





# Бакчабызда бер бала бар...

Бакчабызда бер бала бар —
Шундый да ипле инде:
Кайчак әбием әйткәндәй,
Бигрәк тәртипле инде!

Малайлар һәм кызлар белән
Бик әдәпле сөйләшә.
Үзендә булган тәм-томны
Барсына да өләшә.

Көчсезләрне кыерсытмый,
Рәнҗетми ул кызларны...
Ялгыш кына орынса да:
«Гафу ит!» — ди, кызарып.

Уйнаганда, ул һәммәсен
Көлдерә, шаккаттыра.
Тәрбияче апабыз да
Гел аны мактап тора.

Ул баланың кем икәнен
Син белмисең, мин беләм:
Мактануны белми торган
Ул малай үзем булам!



## Яшәү

Урман шаулый икән,
Кошлар сайрый икән,
Нурлар сибеп, кояш
Җиргә карый икән.

Ай да бага икән,
Чишмә ага икән,
Елгаларда дулкын
Ярга кага икән.

Җилләр исә икән,
Гөлләр үсә икән...
Димәк, мин яшимен!
Димәк, дөнья — исән!



## Нәни димәгез миңа

Нәни димәгез миңа!
Илләр турында уйлыйм,
Җирләр турында уйлыйм мин,
Гөлләр турында уйлыйм.

Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.

Июньнең бер иртәсендә
Нигә ал таң атмаган?
«Көт. Кайтам!» — дип киткән бабам
Ник сугыштан кайтмаган?

Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.

Ишетәм мин кайлардадыр
Зар елыйлар нәниләр.
«Берүк сугыш булмасын!» — дип,
Теләк тели әниләр.

Шулар турында уйлыйм мин...
Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез!

# Без — табигать баласы



Рәсем ясыйм ак кәгазьгә
Төсле буяулар белән:
Юлбарысны ясап куйдым
Төлке-куяннар белән.

Рәсемемдә тычкан белән
Аю бии, бергәләп.
Бал кортлары очып йөри,
Канат җилпи күбәләк.

Мәтәлчек атып уйныйлар
Мәче, керпе, арыслан...
Ташбакалар, пыр туздырып,
Атлар белән ярыша!

Рәсемемдә кошлар сайрый,
Чикерткәләр сикерә.
Балык малайлары белән
Күлдә кәҗә су керә.

Үзе кадәр йөк күтәргән
Бер кырмыска малае.
Маймыл аңа караган да
Кашып тора маңгаен...

Үземне дә, дусларны да
Сыйдырдым мин рәсемгә:
Юан гәүдәле булса да
Сыйды хәтта Рәсим дә!

...Ак кәгазьгә сыйган кадәр
Ясагачтын барсын да,
«Без — табигать баласы!» —
дип
Яздым рәсем астына.







## Портрет

Портрет ясау җиңел түгел,
Ярый әле мин оста:
Тиен кызын, матур итеп,
Ясадым бер минутта!

Буявын да тиз буядым,
Кулым бер дә армады...
...Үземне дә ясый идем —
Урын гына калмады.

## Яшел моң

И ямьле, гүзәл манзара:
Агачлар иле — урман!
Хозур урман өсләренә
Сарыла зәңгәр томан.

Агачлар да, үләннәр дә
Үрелеп карый көнгә...
Урманның яшел моңнары
Агыла тирә-юньгә.





## Нур чәчүче чәчәкләр

Елмаймыйча һәм көлмичә
Торалмыймын бер дә мин:
Нур чәчүче чәчәкләр без:
Күктә — кояш, җирдә — мин!

## Акбай белән кояш

Бакчадагы агачларга
Акбай карап шаккаткан:
Алмагач та, чияләр дә —
Һәммәсе дә ап-актан!

Аптыраган моңа Акбай —
Исе киткән, таң калган:
«Кичә генә кар юк иде,
Кай арада кар яуган?»

Акбайга карап торган да
Кояш елмаеп әйткән:
— Кар яумаган, Акбай дустым,
Агачлар чәчәк аткан!





# Бишек җыры

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка, җиләккә,
Айсылуга бүләккә.


Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әткәсе?
Тимерчегә, чиләккә,
Айсылуга бүләккә.

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әбкәсе?
Тегүчегә, күлмәккә,
Айсылуга бүләккә.

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән бабасы?
Чүлмәкчегә, чүлмәккә,
Айсылуга бүләккә.

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән Айсылу?
Бер кая да китмәгән —
Йоклый икән Айсылу...







# Саумы, август!

Сез менә безне күрегез,
Сез менә безгә карагыз! —
Кояш белән җитәкләшеп,
Августка кереп барабыз...

Баллы алма, ал баланнар
Янып тора көмеш чыктан.
Яшел алан, чәчәк тотып,
Каршыларга йөгреп чыккан!

...Августка кереп барабыз,
Җир җылысын тоеп кына,
Ярсып чапкан яшел яллы
Җәй-толпарны тыеп кына...

Сау бул, июль —
Җиләкле юл!
Саумы, август —
Алмалы дус!







## Йөзем һәм үзем

Бигрәк тәмле бу йөзем!
Бигрәк өлгердер үзем:
Табындагы бар йөземне
Ашап куйдым берүзем!

## Ял итәм

Бөтен өйне җыештырдым,
Ялт иттереп.
Ятам хәзер, үз-үземне
Ял иттереп.



## Хәерле иртә!

Әтәчтән дә иртәрәк
Уяндым мин, әлбәттә:
— Хәерле иртә, әннәм!
Хәерле иртә, әттәм!

Үзем урын җыям мин,
Үзем юына алам...
— Хәерле иртә, әбкәм!
Хәерле иртә, бабам!

Мәктәпкә үзем барам,
Калалар мине мактап...
— Хәерле иртә, апам!
Хәерле иртә, мәктәп!





## Булышчы

Хәтерли ул бик яхшы:
«Әбигә булышкан бар,
Әтигә булышкан бар...
Әни идән юганда,
Идән дә юышкан бар...»

Бүген минә Ләйләгә
Булышып алды әле:
— Бераз гына кабам! — дип,
Кабак чаклы алмасын
Сыпырып салды әле!

Алмадан соң аннары
Чиясе дә калмады,
Конфеты да калмады...
Ләйлә дә тик тормады —
Иреннәрен ялмады.
Минә шулай булышты...
Булышчы.





## Сыерчыклар

Җылы яктан очып килде
Сыерчыклар-кошкайлар.
— Исәнмесез, малайлар! — дип
Дәшә безгә дускайлар.

Куанышып сайрашалар
Кояшлы, аяз күктә.
Без аларга кул болгыйбыз:
— Оябыз әзер күптән!







# Әни бәйрәме

Айсылу да уянган... Күр:
Бәхтияр дә уянган!
Бишектәге Ләйләгөл дә
Уянганга куанган...

Уянганга, куанганга
Бер сәбәп бардыр әле?!
Бар икән шул... Бүген, бүген...
Бүген — Әни бәйрәме!

Әбинең дә, бабайның да
Авызлары җырылган.
Әти, абый чәчәк тотып
Тора табын кырында.

Ник елмая алар бүген?
Белсәң, безгә әйт әле.
— Ник әйтмәскә! Бүген, бүген...
Бүген — Әни бәйрәме!



# Кояшлы яңгыр

Ява яңгыр...
Күктә — кояш
Һәм салават күпере!
Йөзеп йөри ак болытлар,
Ак күбектәй күпереп.

Ява яңгыр...
Һәммәбез дә
Әй сөенә, шатлана.
Күк йөзендә — алсу кояш,
Җирдә — яшел тантана!

Ява яңгыр...
Әй сибәли
Җәйнең җылы яңгыры.
Баш очында серле аһәң —
Төсле җырлар яңгырый.



## Кышкы иртә

Кышкы иртә. Авыл. Тынлык.
Җил әле уянмаган.
Иртә шул: бала-чага да
Чыкмаган урамнарга.
Кошлар күптән хәрәкәттә —
Очып йөриләр инде.
Агайлар да, сукмак ясап,
Карлар көриләр инде.
Тиздән, тиздән җил уяныр —
Сукмакларны себерер.
Балаларның шат авазы
Урамнарга сибелер.





## Кыш — буяучы

Бөтерчектәй бөтерелә,
Әй тирбәлә ак карлар...
Кыш — буяучы, табигатьне
Буяп чыккан, акшарлап!

Куе зәңгәр томан булып,
Урманга эңгер төшә.
«Җиһан тыныч йокласын», — дип,
Җил йөри, мендәр түшәп...

Чиксезлектә, җем-җем балкып,
Йолдызлар нидер көтә.
Шунда очып китәр сыман
Чыршы — яшел ракета!

Ылыс-канатларда — бәсләр,
Яна әнә, елкылдап...
Вакыт безгә алып килә
Яңа ел — яңа китап!



## Буталмыш илендә

Буталмыш дигән илдә
Бервакыт булдым мин дә.
Һәм шунда йөргән мәлдә,
Мин күрдем мондый хәлләр:

Анда кәҗә:
— Мияу! — ди,
— Му-у! — дип, мәче мияулый...

Сабый әйтә:
— Миһаһай!
— Мһау! Мһау! — ди бахбай...

Анда сыер:
— Мәм-мәм! — ди,
— Микикики! — дия маэмай...

Ә бит бездә бүтәнчә,
Бездә: «Мәм-мәм!» — ди мәче...

Туктале, буталдым мин,
Нәрсәдер бутадым мин.
Әйдә, син матур итеп,
Бир әле дөрес әйтеп!



## Кыш бабай җыры

Бигрәкләр дә матур дөнья! —
Җиргә аклык бөркелә...
Гүзәллеккә таңнар калып,
Бер елмаям, бер көләм.
Кешеләрнең бик сагынып
Мине көткәнен беләм.
Шуңа күрә сөенечләр,
Шатлыклар алып киләм.
Өләшермен мин аларны,
Тынычлык, бәхет теләп.
Яңа яуган кардай ап-ак
Биштәрем үзем белән...

## Кар бабайлар

Нәсим дә кар тәгәрәтә,
Вәсим дә кар тәгәрәтә...
Нәни генә булса да, күр,
Рәсим дә кар тәгәрәтә!

Тәгәрәтәм мин дә карны —
Тәгәрәтәм ап-ак шарны...
Кар шар миңа өчәү кирәк —
Тәгәрәтәм тагын карны!..

Эшебезгә карап тордык —
Иллә дә шәп булды, малай:
Кар бабайлар белән безнең
Бөтен урам тулды, малай!







## Күңелле!

Буранлап-буранлап,
Кар яуды:
Урамнар, сукмаклар
Тарайды.

Чыктылар балалар
Урамга.
Урамны киңәйтеп
Уйнарга!

Уйныйлар, көләләр
Үзләре.
Суыктан алланган
Йөзләре.

Кыш көне, әйе шул,
Күңелле!
Сиңа да бу шулай
Түгелме?

## Кызык кыш

Кыш беткәндә... кыш килде —
Быел кыш кызык итте...
Кар яудыра-яудыра,
Кыш тәмам кызып китте!

Башта билдән булган көрт
Мине дә узып китте;
Койманы һәм мунчаны...
Өйне дә узып китте!

...Ярый әле кышның, дим,
Үзен яз кызык итте:
Кояш булып чыкты да
Бөтен карны эретте.

## Апрель

Апрель, апрель...
Ярсып-кайнап,
Бозлар аккан ай да ул.
Апрель, апрель...
Жылы яктан
Кошлар кайткан ай да ул.

Апрель, апрель...
Чәчкәләрне
Сагынып көткән ай да.
Апрель, апрель...
Халкыбызны
Тукайлы иткән ай да!

Апрель, апрель...
Ләйсән яңгыр
Яуган тәүге яз ае.
Апрель, апрель...
Җан-тәннәрне
Иркәләгән наз ае!





## Үзенә охшаган

Айсылу аптырады:
Җыр да җырлап карады,
Сөйләде әкият тә,
Биеп күрсәтте хәтта!

Айсылу аптырады:
Бармак янап карады,
«Конфет бирмим бүтән», — дип
Ачуланып карады...

Юк, курчагы тыңламый —
Йокламый да йокламый!

...Охшаса охшар икән
Айсылуга шулчаклы:
Айсылу йокламыйча
Йокламады курчагы.



# *Кем бәхетле?*

Нилнең бар агач аты:
Ул гел шуңа атлана.
Маэмае да бар Нилнең,
Шуның белән мактана.

Попугае, мәчесе,
Пианиносы да бар...
Юк әйбере генә юк —
Өендә барсы да бар!

— Мин синнән бәхетлерәк! —
Диде шулчак Гыйлемдар.
— Ничек инде? — диде Нил.
— Чөнки минем энем бар!







## Сизми калганбыз...

Җәй узмас диеп
Уйлаган идек:
Таңнан кичкәчә
Уйнаган идек.

Сизми калганбыз
Көз килгәнен дә,
Тәүге яфраклар
Өзелгәнен дә...

Әле һаман да
Сизмәс идек без,
Көзнең килгәнен
Белмәс идек без.

Кыңгырау чыңы
Искә төшерде:
Көзнең килүен
Шунда төшендек.

## Кем кайда яши?

Бүре яши абзарда,
Мәче яши өнендә.
Сарык яши урманда,
Ә төлке — безнең өйдә.

Юк, болай дөрес түгел...
Сарык яши өнендә.
Төлке яши абзарда,
Ә бүре — безнең өйдә.

Юк, тагын дөрес түгел!..
Мәче яши абзарда...
Уф!.. Йәгез инде, берегез
Дөрес әйтеп бирегез!



## Энем әйтә...

Телевизор карадык без:
Күрсәттеләр дөяләр.
Дөяләрнең барсына да
Зур-зур йөкләр төялгән...

Энем әйтә:
— Мин — юлчы, — ди, —
Ә син, абый, дөя бул!
Мин дә сиңа чемоданнар
Һәм капчыклар төярмен!..





## Кайчан ничек

Болытлар балавыз сыга...
Шундый күңелле безгә! —
Нәни-нәни күлләвекләр
Елмая безнең эздә.

Булат та балавыз сыга...
Шундый күңелсез безгә. —
Нишләргә? Энекәшебез
Пычракка баткан тездән...

Әни белән әтидән,
Һай, эләгәчәк безгә!



## Иң зур балык

Уф! Көне буе эш тә эш...
Ял итеп алыйк әле:
Уйнарга да өлгерербез,
Балыкка барыйк әле!

Тотыйк әле балыкның без
Шундый-шундый зурларын...
Тоткач, дус-ишләр янында
Йөрербез, горурланып!

Барыйк тизрәк су буена,
Атла, дускай, кызурак!
Без бүген тотасы балык
Бар балыктан зурырак!



## Сабантуйда

Бабайларым мәйдан тоткан,
Әтием дә бил алышкан...
Мин дә менә Сабантуйга
Әзерләндем быел кыштан.

Көрәшергә уйлыйм мин дә —
Бабай кебек! Әти сыман!..
Ерак бабаларым миңа
«Бирешмә!» дип әйтер сыман...

Бабайларым мәйдан тоткан...
Бүген мин дә бил алышам:
Мин — батырлар нәселеннән,
Мин алардан һич калышмам!





## Нәкыя

Иреннәрен бөрештереп,
Ирек сызгыра белә.
Бармагын авызга кабып,
Барый сызгыра белә...

Ә үземне... Ә үземне —
Әйтеп тә тормыйм инде!

Тик шулай да кайчагында
Мин бик уфтанып куям:
Җилләр чыгарырлык итеп,
Бер сызгырса Нәкыя!

Шундый итеп сызгырырга
Каян өйрәнгән диген?
Кемнән өйрәнгән диген?
Кыз башы белән.
Бигрәк инде...
Һе.



# Эчтәлек

Соклангыч дөнья . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 2
Онытмам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Җил көймәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Матур төш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Бакчабызда бер бала бар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Яшәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Нәни димәгез миңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Портрет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Яшел моң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Без — табигать баласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Нур чәчүче чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Акбай белән кояш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Бишек җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Саумы, август! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Йөзем һәм үзем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Ял итәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Хәерле иртә! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Булышчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Сыерчыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Әни бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Кояшлы яңгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Кышкы иртә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Кыш — буяучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Буталмыш илендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Кыш бабай җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Кар бабайлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Күңелле! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Кызык кыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Апрель . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Үзенә охшаган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Кем бәхетле? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Сизми калганбыз... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Кем кайда яши? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Энем әйтә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Кайчан ничек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Иң зур балык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Сабантуйда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Нәкыя . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37



УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Л47

**Леронов Л. Л.**

Л47 Җил көймәсе : Шигырьләр / Ләбиб Лерон.— Казан : Мәгариф, 2009.— 39 б.: рәс. б-н.

ISBN 978-5-7761-1973-6

Литературно-художественное издание

Для детей младшего школьного возраста

**Леронов** Лемон Леронович
(**Лерон** Лябиб)

*Лодочка-путешественница*

Стихи

Казань. Издательство «Магариф». 2009

*На татарском языке*

Әдәби-нәфис басма

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

**Леронов** Лемон Леронович
(**Лерон** Ләбиб)

*Җил көймәсе*

Шигырьләр

Редакторы *В. Г. Гомәрова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Компьютерда биткә салучысы *Г. Р. Галимҗанова*
Корректоры *Г. Р. Ногманова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.05.2009.
Форматы 60×90 $^1/_8$. Офсет кәгазе. «Букварная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 5,0 + форз.0,5. Нәшер-хисап табагы 5,4 + форз.0,69.
Тиражы 10 000 д. Заказ Т-1353.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru
http://www.magarif.com

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978-5-7761-1973-6

© «Мәгариф» нәшрияты, 2009
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2009